**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

**2021 елның 16 марты** 22 **№**

«Базарлы Матак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2020 елның 23 сентябенрдәге «Җир салымы турында» 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, 2013 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Әлки муниципаль районының «Базарлы Матак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Базарлы Матак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2020 елның 23 сентябрендәге 6 номерлы «Җир салымы турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

«Салым ставкалары»ның 2 статьясына түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«-Алтын Үзән»сәнәгать мәйданчыгында урнашкан җитештерү һәм административ биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм аларга хезмәт күрсәтүче объектларга карата 0,01%»

3. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль районы
Базарлы Матак авыл җирлеге башлыгы: А.Ф.Никошин